| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2017 Казан ш. № 7-8/т

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән "Содружество" акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга тарифның икътисадый нигезле дәрәҗәсен билгеләү турында

"Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында" 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында" 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы, "Тимер юлда ташулар өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары эшләренә (хезмәтләренә) карата тарифларны, җыемнарны һәм түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2009 елның 5 августындагы 643 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең "Россия Федерациясе субъектларында шәһәр яны билгеләнешендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспортында пассажирлар ташу өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә бәяләр (тарифлар) формалаштырганда исәпкә алына торган икътисадый нигезләнгән чыгымнарны хисаплау методикасы раслау турында" 2010 елның 28 сентябрендәге 235-т/1 номерлы, "Тимер юлда ташулар өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары эшләренә (хезмәтләренә) карата тарифлар, җыемнар һәм түләү билгеләү буенча мәсьәләләр карау тәртибен, шулай ук аларны билгеләү (үзгәртү) өчен тапшырылучы документлар исемлеген раслау турында" 2011 елның 19 августындагы 506-Т номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән "Содружество" акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга ун километрлы бер зона өчен 27,89 сум күләмендә икътисадый нигезләнгән тариф дәрәҗәсе билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән "Содружество" акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга икътисадый нигезләнгән тариф дәрәҗәсе билгеләү турында" 25.11.2016 № 7-17/т карарының 1 пунктының көчен югалтуын танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром